**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№10963**
**25.12.2025**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коткару хезмәтләрен булдыру турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Карары, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы приказы, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы буенча чараларны һәрьяклап тәэмин итүне оештыру максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коткару хезмәтләрен булдырырга.

2. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коткару хезмәтләрен формалаштыру һәм алар тарафыннан эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру тәртибен 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коткару хезмәтләре структурасын 2 нче кушымтада каралганча.

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коткару хезмәтләре җитәкчеләренә хезмәтнең оештыру-план документларын эшләргә, килештерергә һәм расларга.

4. Башкарма комитет Карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы;

2) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 8 апрелендәге 2430 номерлы;

3) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 7 декабрендәге 7933 номерлы;

4) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 2 декабрендәге 6794 номерлы;

5) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 маендагы 3876 номерлы;

6) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 июлендәге 5713 номерлы;

7) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 гыйнварындагы 478 номерлы;

8) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 2 декабрендәге 8042 номерлы;

9) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 9 июнендәге 4113 номерлы;

10) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 1 сентябрендәге 7062 номерлы.

5. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 25 декабрендәге
10963 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
коткару хезмәтләрен формалаштыру һәм алар тарафыннан
эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Коткару хезмәте - гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү, авария-коткару формированиеләренең гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү һәм хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә һәм террорчылык актларында башка кичектергесез эшләрне башкару өчен билгеләнгән гражданнар оборонасы идарә органнарының, көчләренең һәм чараларының җыелмасы ул.

2. Коткару хезмәте штабы - хезмәтне тыныч вакыттагы һәм сугыш вакытындагы бурычларны үтәүгә әзерләүгә җитәкчелек итү, хезмәт көчләре һәм чаралары белән идарә итү өчен билгеләнгән хезмәт белән идарә итү органы.

3. Коткару хезмәтләре үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының норматив хокукый актларына, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына таянып эш итәләр.

2 бүлек. Коткару хезмәтләрен формалаштыру

4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коткару хезмәтләре (алга таба – коткару хезмәтләре) булдырыла.

Коткару хезмәтләренең төре һәм саны гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау планнары нигезендә башкарыла торган бурычларның күләмен һәм характерын исәпләү нигезендә билгеләнә.

Коткару хезмәтләренең составы һәм структурасы Башкарма комитет карары белән раслана.

5. Коткару хезмәтләре оештыру-хокукый формаларына һәм ведомство карамагында (буйсынуында) булуына бәйсез рәвештә, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре һәм төп эшчәнлекнең тиешле профильләре буенча берләшә торган шәһәр оешмалары базасында булдырыла.

6. Коткару хезмәтләрен формалаштыру Башкарма комитетның структур бүлекчәләренә һәм (яки) хезмәт составына керә торган һәм аны булдыру өчен иң яхшы шартларга ия оешмага (алга таба - коткару хезмәтен формалаштыручы) йөкләнә.

7. Коткару хезмәтен формалаштыручы хезмәтнең штабын төзи, кирәкле оештыру-план документларын эшли, хезмәт составына керүче оешмаларның идарә органнарын, көчләрен һәм чараларын әзерләүгә методик җитәкчелек итә.

8. Коткару хезмәтләренең штаблары составына хезмәтне формалаштыручы идарә органнарының вазыйфаи затлары, хезмәт составына кертелгән оешмаларның җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары кертелә (килешү буенча).

9. Коткару хезмәтләре тыныч вакытта табигый һәм техноген характердагы, шулай

ук террорчылык актлары аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чараларда катнашу өчен җәлеп ителә.

10. Аның тарафыннан төзелгән гражданнар оборонасы көчләренә карата, тыныч вакытта Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен коткару хезмәтләрен җәлеп итү турында карарны гражданнар оборонасы Җитәкчесе — Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе (алга таба - шәһәр Гражданнар оборонасы Җитәкчесе) кабул итә.

### 3 бүлек. Гражданнар оборонасы хезмәтләре белән җитәкчелек итү

11. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коткару хезмәтләре белән гомуми җитәкчелекне шәһәрнең гражданнар оборонасы Җитәкчесе гамәлгә ашыра.

Коткару хезмәтләре белән турыдан-туры җитәкчелекне әлеге хезмәтләрнең җитәкчеләре гамәлгә ашыра.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коткару хезмәтләре эшчәнлеген координацияләүне Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе гамәлгә ашыра.

### 4 бүлек. Коткару хезмәтләре белән идарә итүне оештыру

12. Коткару хезмәтләре белән идарә итү, хезмәтләрнең һәм аларның штабларының тиешле җитәкчеләре тарафыннан гражданнар оборонасы чаралары үтәлешен тәэмин итү буенча буйсынган идарә органнарына, авария-коткару формированиеләренә, штатта булмаган формированиеләргә даими җитәкчелек итүдән, аларның әзерлеген тәэмин итүдән, тыныч вакыт һәм сугыш вакыты шартларында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү эшчәнлеген оештырудан гыйбарәт.

13. Коткару хезмәтләре белән идарә итүнең нигезе булып хезмәтләр җитәкчеләренең һәм гражданнар оборонасының югарырак җитәкчеләренең карарлары, шулай ук коткару хезмәтләре тарафыннан эшләнә торган:

- коткару хезмәте тарафыннан гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү планы;
- коткару хезмәте тарафыннан табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләрне тәэмин итү планы тора.

14. Коткару хезмәтләре тарафыннан гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итүне планлаштыру Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Коткару хезмәтләренең гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү планнары алар тарафыннан гражданнар оборонасы буенча махсус чаралар оештыруны һәм үтәү тәртибен билгели.

Коткару хезмәте планнарын эшләүне коткару хезмәте җитәкчесе оештыра.

Коткару хезмәтләренең планнары Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча идарәсе белән килештерелә һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең тиешле коткару хезмәтләренең җитәкчеләре тарафыннан раслана.

15. Коткару хезмәтенең бурычлары коткару хезмәте турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

Коткару хезмәте турындагы нигезләмә коткару хезмәте җитәкчесе тарафыннан эшләнә һәм шәһәрнең гражданнар оборонасы Җитәкчесе тарафыннан раслана.

16. Гражданнар оборонасы чараларын һәрьяклап тәэмин итү өчен коткару хезмәтләре:

- гражданнар оборонасы чаралары үтәлешен тәэмин итү буенча штатта булмаган формированиеләрне (алга таба - ГОШФ), штатта булмаган авария-коткару

формированиеләрен (алга таба - ШАКФ) һәм хезмәт эшчәнлеге профиленә туры килә торган гражданнар оборонасы чаралары үтәлешен тәэмин итүче оешмаларны җәлеп итәләр;

- хезмәтләр составына керүче формированиеләрне һәм гражданнар оборонасы бурычларын хәл итү өчен җәлеп ителә торган оешмаларны исәпкә алуны оештыралар.

Коткару хезмәтләре тарафыннан җәлеп ителә торган гражданнар оборонасы чаралары үтәлешен тәэмин итүче ГОШФ, ШАКФ, оешмаларның гомуми саны һәм алардагы кеше саны тыныч вакытта һәм сугыш вакытында хезмәтләр тарафыннан хәл ителә торган бурычларның характеры һәм күләме, кеше ресурслары һәм матди чараларның булуы белән билгеләнә.

17. Коткару хезмәтләренең шәхси составының белемнәрен камилләштерү, күнекмәләрен ныгыту һәм аларның бурычларны үтәүгә әзерлеген бәяләү максатларында гражданнар оборонасы Җитәкчесе - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Гражданнар оборонасы Җитәкчесе карары буенча 5 елга кимендә бер мәртәбә дәвамлылыгы 8 сәгатькә кадәр махсус өйрәнүләр үткәрелә.

## 5 бүлек. Коткару хезмәтләре тарафыннан башкарыла торган функцияләр:

18. Коткару хезмәтләренең гомуми функцияләре булып тора:

- гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү хезмәте планын һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү гамәлләрен тәэмин итү хезмәте планын эшләү һәм тормышка ашыру;

- хезмәт эшчәнлеге профиле нигезендә гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү;

2) коткару хезмәтенең идарә органнарын, көчләрен һәм чараларын булдыру һәм гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү буенча бурычларны үтәүгә әзерләү;

- хезмәт профиле нигезендә матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чараларның кирәкле запасларын булдыру һәм карап тоту;

- коткару хезмәте составына керә торган көчләрне һәм чараларны, аларның шәхси состав белән комплектлануын, техника белән җиһазланышын һәм мөлкәт белән тәэмин ителешен исәпкә алу;

- башка коткару хезмәтләре белән үзара эшчәнлекне оештыру һәм дәвам итү;

- шәхси составны, техниканы, коткару хезмәтләре мөлкәтен заманча зарарлау чараларының, аварияләрнең, катастрофаларның һәм табигый бәла-казаларның зарарлаучы факторларыннан саклауны оештыру.

19. Эшчәнлек профиленнән чыгып, коткару хезмәтләренең төп функцияләре булып тора:

1) инженерлык хезмәтләре:

- гражданнар оборонасының инженерлык-техник чараларын эшләү һәм тормышка ашыру;

- гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм аларның яшәешне тәэмин итү системаларын билгеләнеше буенча файдалануны оештыру ;

- тыныч вакытта һәм гражданнар оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә, җир астында урнашкан бүлмәләрнең халык ышыклану өчен яраклашуын контрольдә тоту;

- тыныч вакытта гражданнар оборонасының тиз төзелә торган, гадиләштерелгән эчке җиһазлары булган саклану корылмаларын һәм гади типтагы ышыклану урыннарын әзерләүне контрольдә тоту һәм гражданнар оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә - төзүне оештыру;

- гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларында халыкның ышыклануын оештыру;

2) сәүдә һәм туклану хезмәтләре:

- сугыш вакыты шартларында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә халыкны азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән нормалаштырып тәэмин итүне оештыру;

- азык-төлек һәм беренче чиратта кирәкле сәнәгать товарлары запасларын саклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

- азык-төлек запасларын гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларына һәм идарә пунктларына туплауны оештыру;

- урнашу районнарында, авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне үткәрү районнарында гражданнар оборонасы чаралары үтәлешен тәэмин итү буенча ГОШФ, ШАКФ шәхси составын тукландыруны тәэмин итүне оештыру;

3) медицина хезмәте:

- гражданнар оборонасы чараларын медицина белән тәэмин итүне планлаштыру һәм оештыру;

- дәвалау-эвакуация чараларын үткәрү;

- халыкка медицина ярдәменең барлык төрләрен күрсәтүне оештыру;

- йогышлы авырулар барлыкка килүне һәм таралуны кисәтү;

- куркынычсыз районнарда кирәкле дәвалау базасын җәелдерү;

4) коммуналь-техник хезмәтләр:

- су белән тәэмин итү системаларының һәм чыганакларының ышанычлылыгын арттыруга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм үткәрү;

- коммуналь хезмәтләрнең сугыш вакыты шартларында эшләргә әзерлеген тәэмин итү, аларның эш итү планнарын эшләү;

- суны чистарту, төчеләндерү һәм транспортлау өчен мобиль чаралар резервын булдыруны һәм әзерләүне контрольдә тоту;

- суүткәргеч станцияләрдә һәм чистарту корылмаларында реагентларның, реактивларның, консервантларның һәм дезинфекцияләү чараларының кирәкле запасларын булдыруны оештыру;

- резервуарлар һәм сыешлыклар, җыела-сүтелә торган үткәргеч торбалар, мобиль резерв һәм автоном энергия чыганаклары, башка кирәкле җиһазлар һәм техник чаралар запасларын булдыруны оештыру;

- дезактивацияләүче, дегазацияләүче һәм дезинфекцияләүче матдәләр һәм эремәләр запасларын булдыруны контрольдә тоту;

- күмәргә мөмкин булган урыннарны алдан билгеләүне оештыру;

- мәетләрне күмү чараларын тәэмин итү өчен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыруны, әзерләүне һәм әзерлектә тотуны оештыру;

5) җәмәгать тәртибен саклау хезмәте:

- җәмәгать тәртибен саклау көчләрен булдыру һәм җиһазландыру;

- җәмәгать тәртибен торгызу һәм саклау, гражданнар оборонасы көчләренең хәрәкәт итү һәм халыкны эвакуацияләү маршрутларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

- авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен ГОШФ, ШАКФ көчләренең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү;

- эчке эшләр органнары тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны, шартнамәләр буенча юридик һәм физик затларның мөлкәтен саклауны көчәйтү, караусыз калган мөлкәтне саклау буенча чаралар күрү;

- законнарда билгеләнгән кагыйдәләрне үтәп, мәетләрне тану һәм исәпкә алу чараларын оештыру һәм үткәрү;

6) янгынга каршы хезмәтләр:

- янгынга каршы кирәкле көчләр булдыру, аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә җиһазландыру һәм әзерләү;

- сугыш вакытында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне үткәрү районнарында янгын сүндерүне оештыру;

- аеруча мөһим объектларда янгыннарны сүндерүне оештыру.

7) элемтә һәм хәбәр итү хезмәтләре:

- халыкка үзәкләштерелгән хәбәр итү системасын булдыру һәм аны даими әзерлек хәлендә тоту, яңа буын техник чаралары базасында модернизацияләүне гамәлгә ашыру;

- локаль хәбәр итү системаларыннан файдалану;

- кешеләр күпләп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм белдерүнең махсуслаштырылган техник чараларыннан файдалану;

- Россия Федерациясе бердәм электр элемтәсе челтәре чараларыннан, чыбыклы радио һәм телевизион тапшырулар челтәрләре чараларыннан һәм мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларыннан комплекслы файдалану;

8) транспорт хезмәтләре:

- халыкны транспортның барлык төрләре белән эвакуацияләүне, эшче сменаларны алып баруны (алып кайтуны), саклау корылмаларын төзү өчен материаллар алып баруны, шәһәр читендәге зонага матди һәм мәдәни кыйммәтләр, уникаль җиһазлар, азык-төлек һәм башка матди чаралар чыгаруны, зарарлану чыганакларында, шулай ук гадәттән тыш хәлләр районнарында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне үткәрү өчен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын алып баруны оештыру;

9) ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү хезмәтләре:

- НФГО, НАСФ һәм гражданнар оборонасы чараларын үткәрүгә җәлеп ителә торган оешмаларның автомобиль, инженерлык һәм махсус техникасын ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү чараларын оештыру һәм үткәрү;

10) юл хезмәтләре:

- гражданнар оборонасы чараларын юл-күпер белән тәэмин итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- юлларны һәм күперләрне ремонтлау, торгызу һәм әзер килеш тоту;

- гражданнар оборонасы көчләренең хәрәкәт маршрутларында һәм эвакуация маршрутларында урау юллар булдыру;

11) энергетика хезмәтләре:

- яктылык һәм башка төр маскировканы гамәлгә ашыру чараларын үткәрү өчен кирәкле матди-техник чараларның запасларын булдыруны һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тотуны оештыру һәм контрольдә тоту;

- энергия белән тәэмин итү системаларының һәм чыганакларының эшләп тору ышанычлылыгын арттыруга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм үткәрү;

12) санитар-эпидемиологик күзәтчелек хезмәтләре:

- хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында зыян күргән халык арасында санитария-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

13) мәдәни кыйммәтләрне саклау хезмәте:

- шәһәр территориясендә урнашкан мәдәни кыйммәтләрне, тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне яклауга һәм саклауга юнәлдерелгән чараларны планлаштыруны һәм үткәрүне оештыру.

## 6 бүлек. Коткару хезмәтләрендә эшләнә торган документлар исемлеге

20. Коткару хезмәтләрендә түбәндәге документлар эшләнә:

1) коткару хезмәте җитәкчесенең штаб төзү турындагы приказы;

2) коткару хезмәтенең штат-вазыйфа исемлеге;

3) коткару хезмәте турында нигезләмә;

4) коткару хезмәте вазыйфаи затларының функциональ бурычлары;

5) коткару хезмәте тарафыннан гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү планы;

6) коткару хезмәте тарафыннан табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү гамәлләрен тәэмин итү планы»;

7) коткару хезмәте башлыгының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерү гамәлләрен тәэмин итү буенча эш картасы;

8) коткару хезмәтенең хәбәр итү һәм элемтә схемасы;

9) коткару хезмәте җитәкчесенең түбәндәге кушымталар белән «Агымдагы елда коткару хезмәтен әзерләү йомгаклары һәм чираттагы елга бурычлар турында» приказы:

- өйрәнүләр һәм күнегүләр тематикасы;
- уку төркемнәре, дәрес җитәкчеләре исемлеге;
- дәресләр расписаниесе;
- дәресләрне исәпкә алу журналлары;

10) төзелгән һәр формированиене әзерлеккә китерү планы;

11) мөлкәт, техника алуга заявкалар, нарядлар, накладнойлар, ышаныч язулары;

12) элемтә узелларының һәм вазыйфаи затларның позывнойлар таблицасы;

13) алынган һәм бирелгән күрсәтмәләрне (командаларны, сигналларны) исәпкә алу журналы;

21. Формальләштерелгән документлар:

1) коткару хезмәтенең торышы турында белешмә-доклад;

2) гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм төрле характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча коткару хезмәте җитәкчесенең карар проектлары;

3) гражданнар оборонасы чараларын үтәү буенча гражданнар оборонасы җитәкчесенә тәкъдимнәр формаларының үрнәкләре;

4) гражданнар оборонасы мәсьәләләре буенча хәбәр формасы үрнәкләре.

## 7 бүлек. Коткару хезмәтләрен комплектлау, матди-техник һәм финанс белән тәэмин итү тәртибе

22. Коткару хезмәтләрен шәхси состав белән комплектлау, базасында алар булдырыла торган оешмалар һәм төп эшчәнлекнең тиешле профильләре буенча берләшә торган җәлеп ителүче оешмалар хисабына, тиешле хезмәтләрнең җитәкчеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

23. Сугыш вакытында коткару хезмәтләрен автомобиль транспорты, юл-төзелеш һәм күтәртү-транспорт техникасы белән тәэмин итү мобилизация планнары буенча хәрби һәм башка аеручა мөһим йөртүләргә алынмаган ресурслар хисабына башкарыла.

24. Гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау чараларын финанслау Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2025 елның 25 декабрендәге
10963 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
коткару хезмәтләре структурасы

| № т/б | Коткару хезмәтенең исеме | Коткару хезмәтен булдыручы оешма исеме | Ф.И.А.и. | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Хезмәт башлыгы | Хезмәт штабы башлыгы |
| 1. | Инженерлык | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе | Габделхаков Илфат Ришат улы | Лотфрахманов Динар Илдар улы |
| 2. | Сәүдә һәм туклану | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге | Солтанова Рәисә Кәүсәр кызы | Зыятдинова Елена Петровна |
| 3. | Медицина | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча) | Ногманов Рөстәм Марат улы (килешү буенча) | Борһанова Айгөл Әбүзәр кызы (килешү буенча) |
| 4. | Коммуналь-техник | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Вилданов Руслан Флер улы | Максимова Регина Геннадьевна |
| 5. | Җәмәгать тәртибен саклау | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе (килешү буенча) | Нәҗмиев Раил Радик улы (килешү буенча) | Солтанов Марат Фарасат улы (килешү буенча) |
| 6. | Янгынга каршы | ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 нче янгын сүндерү-коткару отряды (килешү буенча) | Мифтахетдинов Алмаз Шәйхенур улы (килешү буенча) | Хәйретдинов Марат Шамил улы (килешү буенча) |
| 7. | Элемтә һәм хәбәр итү | «Таттелеком» ААҖ филиалы – Яр Чаллы зональ электр элемтәсе узелы (килешү буенча) | Степанов Максим Александрович (килешү буенча) | Устинов Андрей Юрьевич (килешү буенча) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8. | Транспорт | Башкарма комитет шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенең транспорт һәм элемтә бүлеге | Гозәеров Равил Габдрәхим улы | Полевик Гөлнара Фоат кызы |
| 9. | Ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү | «Татнефть-АЗС Центр» ҖЧҖнең Чаллы филиалы (килешү буенча) | Хәбибрахманов Рәшит Гыйльфан улы (килешү буенча) | Вдовьев Сергей Владимирович (килешү буенча) |
| 10. | Юл | «Автомобиль юллары предприятиесе» ҖЧҖ (килешү буенча) | Черкашин Илья Игоревич (килешү буенча) | Хөснетдинов Илнур Рафис улы (килешү буенча) |
| 11. | Энергетика | «Челтәрләр компаниясе» АҖ филиалы – Яр Чаллы электр челтәрләре (килешү буенча) | Шаронов Эдуард Павлович (килешү буенча) | Сәлахов Марат Марс улы (килешү буенча) |
| 12. | Санитар-эпидемиологик күзәтчелек | Росия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтенең Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш, Тукай, Минзәлә районнарындагы территориаль бүлеге (килешү буенча) | Нәфигуллина Лемуза Рульевна (килешү буенча) | Ризванов Данияр Әзһәт улы (килешү буенча) |
| 13. | Мәдәни кыйммәтләрне саклау | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Кәрамиев Румил Рәүф улы | Закирова Гөлназ Вәдир кызы |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева